ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Площадь Победы, 4, город Бавлы,
423930

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Җиңү мәйданы, 4, Баулы шәһәре,
423930

Тел.: (85569) 5-29-50, факс: (85569) 5-38-72. E-mail: Bavly.Gorispolkom@tatar.ru,
сайт: www.bavly.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.09.2021 Баулы шәһәре №93

Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 июнендәге 76 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 июнендәге 76 номерлы карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.5 пунктның 2-9 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентта дәүләт адреслы реестрын алып баруга һәм федераль мәгълүмат адреслы системасын эксплуатацияләүгә бәйле булган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 28 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 декабрендәге 1221 номерлы карары «Адресларны бирү, үзгәртү һәм бетерү кагыйдәләрен раслау турында» нигезендә төгәл файдаланыла.

1.2. 1.5. пунктның 10 - 16 абзацларын 3 - 8 абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

«Баулы шәһәре» муниципаль
берәмлеге Башкарма
комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров